**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләкләре буенча Татарстан Республикасы Президенты каршындагы комиссия составына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләкләре буенча Татарстан Республикасы Президенты каршындагы комиссия эшчәнлеген камилләштерү максатларында, шулай ук аерым затларның башка эшкә күчүе белән бәйле рәвештә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләге турында» 2004 елның 31 декабрендәге ПУ-824 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2005 елның 7 декабрендәге ПУ-479 номерлы, 2009 елның 29 гыйнварындагы ПУ-35 номерлы, 2011 елның 7 сентябрендәге ПУ-549 номерлы, 2013 елның 7 мартындагы ПУ-208 номерлы, 2014 елның 15 мартындагы ПУ-275 номерлы, 2015 елның 2 мартындагы ПУ-196 номерлы, 2016 елның 11 мартындагы ПУ-236 номерлы һәм 2018 елның 21 апрелендәге ПУ-329 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләкләре буенча Татарстан Республикасы Президенты каршындагы комиссия (алга таба – Комиссия) составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Комиссия составыннан Э.Р. Камалованы чыгарырга;

б) Комиссия составына кертергә:

Әюпова Ирада Хафизҗан кызын – Татарстан Республикасы мәдәният министрын, аны Комиссия рәисе урынбасары итеп расларга;

Сладковский Александр Витальевичны – Татарстан Республикасы Дәүләт симфоник оркестры сәнгать җитәкчесен – баш дирижерын (килешү буенча);

Фомин Анатолий Алексеевичны – Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы рәисен (килешү буенча);

в) Комиссия әгъзалары вазыйфалары атамаларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Ф.Р. Бикчәнтәевнең – «Россия Федерациясенең Театр әһелләре берлеге (Бөтенроссия театр җәмгыяте)» гомумроссия җәмәгать оешмасы бүлекчәсе –

Татарстан Республикасы театр әһелләре берлеге рәисе, Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт Академия театры баш режиссеры (килешү буенча)»;

Р.И. Вәлиевнең – «Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе, шагыйрь (килешү буенча)»;

З.Ф. Гыймаевның – «Татарстан Республикасы Рәссамнар берлеге» төбәк иҗат оешмасы рәисе (килешү буенча)»;

Р.Ф. Кәлимуллинның – «Татарстан Республикасы Композиторлар берлеге» төбәк иҗат оешмасы рәисе (килешү буенча)»;

Г.Р. Нигъмәтуллинаның – «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Мәдәният һәм Татарстан Республикасы халыклары телләрен үстерү идарәсе башлыгы»;

И.И. Сираҗиевның – «Россия Рәссамнар берлеге» бөтенроссия иҗади иҗтимагый оешмасының «Татарстан Рәссамнар берлеге» төбәк бүлекчәсе рәисе (килешү буенча)»;

А.Я. Славутскийның – «В.И. Качалов исемендәге Казан академия рус зур драма театры сәнгать җитәкчесе – директоры (килешү буенча)»;

И.Р. Ягъфәровның – «Россия Федерациясе Кинематографиячеләр берлеге» гомумроссия иҗтимагый оешмасының Татарстан Республикасы төбәк бүлекчәсе идарәсе рәисе (килешү буенча)».

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ • АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2019 ел, 08 февраль
№ ПУ-89